КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 декабрь г.Казань № 1654

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия һәм чит ил мәгариф һәм фәнни оешмаларында гражданнарны әзерләүгә һәм стажировкалауга «Алгарыш» Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең гранты турында» 2021 ел, 26 июль, 646 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия һәм чит ил мәгариф һәм фәнни оешмаларында гражданнарны әзерләүгә һәм стажировкалауга «Алгарыш» Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең гранты турында» 2021 ел, 26 июль, 646 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 17 март, 265 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Россия һәм чит ил мәгариф һәм фәнни оешмаларында гражданнарны әзерләүгә һәм аларның стажировкасына «Алгарыш» Татарстан Республикасы Хөкүмәте гранты турындагы нигезләмәдә:

1.3 пунктта:

өченче абзацта «юридик зат» сүзләрен «индивидуаль эшкуар, юридик зат» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «индивидуаль план буенча һәм мөрәҗәгать итүче раслый торган бирем нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аккредитацияләнгән мәгариф оешмасы - дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирү оешмасы;»;

1.4 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Профессионаллар» - Һөнәри осталык буенча бөтенроссия чемпионат хәрәкәте конкурсантлары һәм (яисә)экспертлары исәбеннән грант эзләүчеләргә - стажировкага;»;

1.6 пунктның беренче абзацында «Worldskills» сүзен «Профессионаллар» сүзенә алмаштырырга;

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Грантны алуга катнашу өчен, әлеге Нигезләмәнең 4.5 - 4.11, 4.13 пунктларында билгеләнгән документларның электрон күчермәләрен кушып, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә www.uslugi.tatarstan.ru сайты аша һәм (яисә) документларны Министрлыкка кәгазь чыганакта гариза бирү срогының соңгы көненнән дә соңга калмыйча тапшырырга кирәк.»;

4.4 пунктның беренче абзацында «Worldskills» сүзен «Профессионаллар» сүзенә алмаштырырга;1

4.5 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

4.11 пунктта:

беренче абзацта «Worldskills» сүзен «Профессионаллар» сүзенә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аккредитацияләнгән белем бирү оешмасында алынган һөнәри белем булу, йә урта һөнәри яисә югары белем бирү мәгариф оешмасында белем алу, йә Һөнәри осталык буенча бөтенроссия чемпионаты хәрәкәтен үстерүдә катнашучы оешмаларның хезмәткәре вазыйфасы булу;»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант алырга теләүче конкурсант, компетенция менеджеры, эксперт-остаз, эксперт-методист һәм (яисә) Һөнәри осталык буенча бөтенроссия чемпионаты хәрәкәтендә катнашучы булуын раслаучы документлар булу;»;

җиденче абзацта «Worldskills» сүзен «Профессионаллар» сүзенә алмаштырырга;

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«конкурсант, компетенция менеджеры, эксперт-остаз, эксперт-методист һәм (яисә) төбәк операторы (төбәк координация үзәге) тарафыннан бирелгән яисә таныкланган катнашучы статусын раслый торган документ;»;

4.19 пунктның икенче абзацында «Worldskills» сүзен «Профессионаллар» сүзенә алмаштырырга;

6.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Әлеге Нигезләмәнең 1.4 пунктының икенче - сигезенче абзацларында билгеләнгән категорияләр буенча грант алучылар әзерлек яисә стажировка тәмамлану турында документны алган көннән 30 календарь көн эчендә әлеге Нигезләмәнең 4.19 пунктында күрсәтелгән нәтиҗәләргә ирешү турында хисап, әлеге Нигезләмәнең 7 нче кушымтасы нигезендә, төзелгән килешү нигезендә эшкә урнашуны раслый торган документлар, әзерлек яисә стажировка узу турында иҗади хисап, әзерлек яисә стажировкасын уңышлы узу турында документларның күчермәләре белән әлеге Нигезләмәнең 7 нче кушымтасы нигезендә хисап тапшыра.

Чит илдә белем алу һәм (яисә) чит ил квалификациясе турындагы документлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рус теленә тәрҗемә ителергә тиеш. Әлеге Нигезләмәнең 1.4 пунктының икенче - сигезенче абзацларында билгеләнгән категорияләр буенча грант алучылар тарафыннан тапшырылган очракта, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче аккредитацияләнгән мәгариф оешмаларында магистратура һәм (яисә) аспирантура программалары буенча укуны алга таба узу турындагы документлар хезмәткә урнаштыру йөкләмәләрен үтәү срогына кертелә.».

әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасында:

таблицаның 1.3 пункты үз көчен югалткан дип танырга;

таблицаның 7 бүлеге исемендә «Worldskills» сүзен «Профессионаллар» сүзенә алмаштырырга;

7.1 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Аккредитацияләнгән белем бирү оешмасында алынган һөнәри белем булу, йә урта һөнәри яисә югары белем бирү мәгариф оешмасында белем алу, йә Һөнәри осталык буенча бөтенроссия чемпионаты хәрәкәтен үстерүдә катнашучы оешмаларның хезмәткәре вазыйфасы булу»;

7.2 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Грант алырга теләүче конкурсант, компетенция менеджеры, эксперт-остаз, эксперт-методист һәм (яисә) Һөнәри осталык буенча бөтенроссия чемпионаты хәрәкәтендә катнашучы булуын раслаучы документлар булу;»;

әлеге Нигезләмәгә 7 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә;

әлеге карар белән расланган «Алгарыш» Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Россия һәм чит ил мәгариф һәм фәнни оешмаларында гражданнарны әзерләүгә һәм стажировкалауга грант бирү буенча республика комиссиясе турында нигезләмәнең 5 пунктындагы сигезенче абзацында «Worldskills» сүзен «Профессионаллар» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Россия һәм чит ил мәгариф һәм фәнни оешмаларында гражданнарны әзерләүгә һәм аларның стажировкасына «Алгарыш» Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантын бирү буенча республика комиссиясе составында:

«Яшь галимнәр», «Ике диплом» категорияләре буенча грант алырга теләүчеләр арасыннан грант алуга сайлап алуны үткәрү буенча ярдәмче комиссиясе составыннан А.Ю.Копыловны, А.А.Шинкаренконы чыгарырга;

«Яшь галимнәр», «Ике диплом» категорияләре буенча грант алырга теләүчеләр арасыннан грант алуга сайлап алуны үткәрү буенча ярдәмче комиссиясе составына кертергә:

| | |
|---|---|
| Сафин Руслан Рушан улын | «Казан илкүләм тикшеренү технологик университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фәнни эшләр һәм инновацияләр буенча проректоры вазыйфаларын башкаручы |
| Умарова Оксана Андреевнаны | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге башлыгы урынбасарын; |

«Worldskills» категориясе буенча грант алырга теләүчеләр арасыннан грант алуга сайлап алуны үткәрү буенча ярдәмче комиссия исемендә «Worldskills» сүзен «Профессионаллар» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин